**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ**

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур., 29 нчы йорт. Тел.3-44-56

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29, Тел. 3-44-56

**КАРАР**
от «16» сентябрь 2019 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
№ 20

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында” Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Уставының 12 статьясы нигезендә

**1. Карар бирәм:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"Сез 2019 елда үзара салымның бер тапкыр түләвен кертү белән килешәсезме 500 (биш йөз) сум, Иске Кормаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан кала, алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында:

- Ритуал хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын тәртиптә тоту;
- Авыл җирлегендә уңай шартлар тудыру: авылларда урам утларын карап тору;
- Халыкның ялын оештыру өчен шартлар тудыру һәм урыннар көйләү;
- Авыл эченә кергән юлларны карау;
- Авыл җирлегендә халыкны су белән тәэмин итү, су кертү һәм чыгаруны көйләү.

“ӘЙЕ” “ЮК”

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: ТР, Актаныш муниципаль районы, Иске Кормаш авылы, Үзәк урамы 26 нчы йортта урнашкан МБУ “Иске Кормаш мәдәният йорты; ТР, Актаныш муниципаль районы, Иске Балтач авылы, Үзәк урамы 29 нчы йортта урнашкан авыл клубы; Яңа Балтач авылы, Үзәк урамы 3 нче йортта урнашкан җәмәгать үзәге; Кыр-Каентүбәч авылы, Үзәк урамы 38 нче йортта урнашкан авыл клубы; Шәбезбаш авылы, Үзәк урамы 21 нче нчы йортта урнашкан авыл клубы, ТР, Актаныш муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә Кашбразиев